ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 555-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, С.А. Вострикова, Д.Р. Барыев, Н.К. Шимина тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 555-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2512-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М: Захарова, С.А. Вострикова,
Д.Р. Барыев, Н.К. Шимина
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1) 7 статьяның 1 өлешендәге 14 пунктына «һәм яшь хезмәткәрләрнең» сүзләрен өстәргә;

2) 8 статьяның 6 өлешендәге 3 пунктында татарча текст үзгәрешсез кала.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 22 апрелендәге № 95-ФЗ номерлы Федераль закон белән хезмәт юлын яңа гына башлый торган, һөнәри күнекмәләр ала торган һәм эш стажы туплый торган яшь гражданнарга ярдәм итү максатында «яшь хезмәткәр» категориясе кертелә. Кертелгән үзгәрешләр буенча, «яшь хезмәткәр» – хезмәт стажы өч елдан артык булмаган һәм «яшь белгеч» категориясенә карамаган 35 яшькә кадәрге (35 яшьне дә кертеп) Россия Федерациясе гражданы (әгәр Россия Федерациясе субъекты законнары белән башкасы билгеләнмәгән булса).

Шуңа бәйле рәвештә «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» Федераль закон белән билгеләнгән яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру юнәлешләре дә үзгәрә.

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законында кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы төшенчәләр белән бер үк мәгънәдә кулланылганга күрә, карала торган закон проекты белән Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына гына үзгәреш кертергә тәкъдим ителә. Әлеге үзгәреш, Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру юнәлешләренең берсе буларак, яшь хезмәткәрләрнең һөнәри үсешенә ярдәм итүне күздә тота.

8 статьяның 6 өлешенә редакцияләү характерындагы үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында»
Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына
үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә
бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга,
үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы
законнары һәм башка норматив хокукый актлары
ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.